Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы
муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе
«Ю.А.Гагарин исемендәге өченче санлы урта гомуми белем мәктәбе»

| КАРАЛДЫ | КИЛЕШЕНДЕ | РАСЛЫЙМ |
|---|---|---|
| Педагогик киңәшмә утырышы беркетмәсе<br>« 29.08 » 2025 нче ел | Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары<br>_______ /В.М. Горбунова / | 160 нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде «29.08» 2025 нче ел Мәктәп директоры<br>/Л.А.Шафикова/ |

«Илһам –театр түгәрәге» өстәмә дәресенең
эш программасы 2025 -2026 уку елы 2-8 нчы сыйныф
укучыларның яшьләре: 9-14 яшь
гамәлгәашыру вакыты: 1 ЕЛ

Җитәкчесе:
Хәсәнова Флёра Әһлиулла кызы,
әйдәп баручы мәктәп китапханәчесе

## Аңлатма язу

Программа мәктәпнең үсеш программасы һәм өстәмә белем бирү планы нигезендә төзелә. Түгәрәк эше формасында гамәлгә ашырыла.
Эш программасы 3-8 нчы сыйныф укучылары өчен атнага 4 сәгать исәбеннән төзелә. Барлыгы 136 сәгать.
Белем һәм тәрбия бирү бер-берсеннән аерылгысыз. Дәресләрдә алган белемнәрне мәктәптәге түгәрәкләрдә, факультатив дәресләрдә,электив курсларда камилләштерү, тулыландыру һәм ныгыту бүген көнүзәк мәсьәләләрнең берсе.

Баланың мәктәптән нинди шәхес булып чыгуында, киләчәктә нинди һөнәр сайлавында укыту - тәрбия эшенең роле бик зур. Укытучы баланың сәләтен күрә белергә һәм тиешле юнәлеш бирергә тиеш. Тиешле түгәрәккә яздыруның беренче максаты – баладагы мавыгуларны, омтылышларны үстерү, аңа сәләтен табуда һәм камилләштерүдә булышу. Икенче максат – балада эчке табигый көчләрне үстерү.

Балаларының сөйләм телен үстерү дәрестән тыш оештырылган эшләр аша алып барыла.

Балаларның чиста, төзек әдәби телдә сөйләшергә өйрәтү, татар сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, китап укуга кызыксыну уяту, үзләрендә язу теләге уяту максатыннан түгәрәкләр оештырыла.

**Программаның максаты:**

Балаларның сәнгати һәм эстетик культурасын үстерү, аларга тормышта яхшылык һәм матурлыкны күрергә өйрәтү;

**Бурычлар:**

1) Театр сәнгате белән гомуми таныштыру.
2) Театрга нигез салучылар, танылган артистлар белән таныштыру.
3) Драма әсәрләрен өйрәнүгә теләк уяту.
4) Төрле жанрдагы әсәрләрне сәхнәгә кую аша укучыларның табигатьтән бирелгән сәләтләрен үстерү.
5) Сәхнәдә үзеңне тоту осталыгын, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.
6) Мәктәп күләмендә оештырылган бәйрәм, тамашаларда, район, республика күләмендә уздырылган конкурсларда актив катнашу.

## Программаның актуальлеге

Федераль дәүләт стандартларын гамәлгә ашыру шартларында мәгариф алдына һәр яктан камил, мөстәкыйль һәм иҗади шәхес тәрбияләү максаты куелды. Укучыларга дәресләрдән тыш өстәмә белем бирү дә – заман куйган таләпләрнең берсе. Программа әлеге максатка ярашлы шәхесне үстерүгә юнәлдерелгән технология нигезендә эшләнде.

## Түгәрәк эше буенча көтелгән нәтиҗәләр :

-укучы үзен иркен тотарга өйрәнә, психологик яктан ачыла;
-үзенең мавыгуына туры килгән эш белән шөгыльләнә;
-түгәрәктәге укучылар, укытучы белән аралашу вакытында, эчке дөньясында ачыла, аралашу әдәбенә өйрәнә;
-укучы фикерләргә, үз фикерен дәлилләргә өйрәнә;
-сөйләм телен камилләштерә ;
-әхлак һәм зәвык тәрбиясе ала;
-шәхес булып тәрбияләнә, үз урынын таба;
-татар теле һәм әдәбияты буенча белемен тирәнәйтә, кызыксыну уята.

Түгәрәк татар теле һәм әдәбияты программасын кабатларга тиеш түгел.

Түгәрәкнең эш формасы күп төрле, монда укытучының иҗади сәләте зур роль уйный. Китап уку, аның турында фикер алышу, кечкенә докладлар төзү, язучы иҗатын өйрәнү, шигырь укучылар бәйгеләрендә катнашу, әдәби - музыкаль монтаж әзерләү, халык театры белән танушу, һ.б. бик күп төрле эш алымнары бар. Түгәрәкләрдә техник чаралар да куллану кирәк, эш барышында музыка яңгырату, магнитофон, телевизор, компьютер куллану эшне тагын да җанландыра.

Түгәрәк эше балаларның күзаллавын киңәйтергә, аңа яңалык алып килергә, рухи тәрбия бирергә дә тиеш. Халык авыз иҗатын, татар халык педагогикасын куллану, табигать белән аралашу түгәрәк эшләрен оештырганда укытучыга зур мөмкинлекләр ача.

## Программаның эчтәлеге

Татар театрының чишмә башы. Театрга нигез салучылар турында кыскача белешмә. Театр артистлары турында фикер алышу.
Татарстандагы театрлар. Театр артистлары турында белешмә.
“Сәйяр” труппасы, аны оештыручы Габдулла Кариев эшчәнлеге. Беренче татар хатын-кыз актрисасы С.Гыйззәтуллина-Волжская иҗаты.
Г.Камал һәм К.Тинчурин - татар театрын оештыручылар. Аларның эшчәнлегенә күзәтү.
Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия, Курчак театры белән танышу.
Спектакльне сәхнәгә кую. Рольләрне бүлешү. Сәхнә бизәлеше өчен декорацияләр, костюмнар әзерләү. Репетицияләр үткәрү. “әсәрне укучылар алдында күрсәтү.
“Син театр турында нәрсәләр беләсең?” темасына викторина уздыру.
“Шигъри сәхнә” исемле шигырьләрне сәнгатьле уку конкурсы уздыру. “Театр яктылыкка, нурга илтә” кичә уздыру.
Баулы халык театрына экскурсия оештыру.

## Универсаль уку гамәлләре:

<u>Шәхескә юнәлтелгән УУГ (универсаль уку гамәлләре)</u>

- Балаларның эстетик зәвыгын, иҗади фантазияләрен үстерү;
- иптәшеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасын күрсәтү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;
- үз фикереңне әйтә белү;
- үз уңышларың -уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү;
- биремнәр системасында ориентлашырга өйрәнү.

<u>Танып белу универсаль уку гамәлләре:</u>

- Үзеңне бәяли белү;
- күренешләрне сурәтләү;
- тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару;
- анализ, гомумиләштерү нигезендә нәтиҗә чыгару

Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре

– көч һәм энергия туплау, конфликтларны һәм каршылыкларны чишү максатында ихтыяр көчен үстерү;
– үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
– үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
– тормыш тәҗрибәсен куллану;
– үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре

- тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;
- сәхнә осталыгы;
- фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру;
- сәхнәдә төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп сөйләү, үзеңне иркен тоту;
- иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү.

**Тематик эш планы**

| № | Содержание и виды работы | Количество часов | | всего |
|---|---|---|---|---|
| | | теория | практика | |
| 1. | Театр дөнясында | **12** | | |
| | Татар дөньясында беренче театр оешу | 2 | | |
| | Татарстандагы театрлар. Театр артистлары турында белешмә | 2 | | |
| | Габдулла Кариев һәм “Сәйяр” труппасы эшчәнлеге. | 2 | | |
| | Татар театрын оештыручылар. | 2 | | |
| | Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия, Курчак театры белән танышу. | 2 | | |
| | Халык театрлары белән танышу | 2 | 2 | |
| 2 | Сәхнә әсәрләре белән танышу- икенче бүлек | **12** | 10 | |
| 3 | Рольләрне бүлү, әсәрдән өзекне сәхнәләштерү. | **12** | 22 | |
| 4 | Декарация һәм костюмнар өстендә эшләү. | **10** | 20 | |
| 5 | Спектакльне сәхнәгә кую | **6** | 6 | |
| 6 | Экскурсияләр, конкурслар. Әзерлек һәм катнашу | **5** | 5 | |
| 7 | Сәхнә артистлары белән очрашулар, торле чаралар | **2** | 2 | |
| 8 | Халык уеннары, йолалары, сәнгатле сөйләм | **4** | 4 | |
| | | | | |
| 9 | Йомгаклау | 2 | | |
| | Барлыгы | 65 | 71 | 136 |

**Көтелгән нәтиҗәләр һәм аларны тикшерү төрләре**

Балалар уку елы ахырына матур итеп шигырь, әкият сөйләргә, аларны сәхнәләштерергә өйрәнергә, үз-үзләрен сәхнәдә матур, иркен итеп тота белергә тиешләр.

- сәнгатле итеп шигырь сөйләү
- “ Театр атналыгында”, “Туган тел”, “ Китап бәйрәмендә”, “Татар сүзе”, “Җәлил укулары”, “Тукай моңы” конкурсында чыгышлар ясау.

КАЛЕНДАРЬ – ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| № | Тема | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт | |
| 1. | Татар дөньясында беренче театр оешу, беренче “карлыгачлары” турында фикер алышу.Видио тасма карау. | 2 сәг. | 2.09.2025 | | |
| 2. | Татарстандагы театрлар. Театр артистлары турында белешмә. | 2 сәг. | 4.09.2025 | | |
| 3. | Габдулла Кариев һәм “Сәйяр” труппасы эшчәнлеге. | 2 сәг. | 9.09.2025 | | |
| 4. | Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин – татар театрын оештыручылар. | 2сәг. | 11.09.2025 | | |
| 5. | Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия, Курчак театры белән танышу. | 2 сәг. | 16.09. 2025 | | |
| 6. | Халык театрлары,БТХТ танышу | 2 сәг. | 18.09.2025 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Практика | 2сәг. | 23.09. 2025 | | |
| 8. | Сәхнәгә кую өчен һәм “Җәлил укулары” конкурсына әсәр эзлзү | 2 сәг. | 25.09. 2025 | | |
| 9. | Практика | 2сәг. | 02.10. 2025 | | |
| 10. | Әсәр эзлэү | 2 сәг. | 07.10.2025 | | |
| 11. | Әсәрне уку | 2сәг. | 09.10. 2025 | | |
| 12. | Әсәрне уку,видеоязмасын карау. | 2 сәг. | 14.10.2025 | | |
| 13. | Практика | 2 сәг. | 16.10.2025 | | |
| 14. | Әсәрнең рольләрен бүлешү. | 2 сәг. | 21.10.2025 | | |
| 15. | Практика. Конкурс өчен әсәрләрне видиотасмага яздыру. | 4 сәг. | 23.10. 2025<br>28.10. 2025 | | |
| 16. | Әсәр өстендә эшләү | 2 сәг. | 30.10. 2025 | | |
| 17. | Практика. “Җәлил укулары” конкурсын да катнашу. | 4 сәг. | 04.11.2025<br>06.11.2025 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 18. | әсәр өстендә эшләү | 2 сәг. | 11.11. 2025 | | |
| 19. | Сөйләм өстендә эшләү | 2 сәг. | 13.11. 2025 | | |
| 20. | Практика. Сәнгатле сөйләм. | 2 сәг. | 18.11.2025 | | |
| 21. | Әсәрне өйрнү | 2 сәг. | 20.11. 2025 | | |
| 22. | Практика | 2 сәг | 25.11. 2025 | | |
| 23. | Әсәр өстендә эшләү | 2 сәг. | 27.11 2025 | | |
| 24. | Практика | 2 сәг | 02.12. 2025 | | |
| 25. | Практика.Спектакльдән өзек өчен костюмнар һәм сәхнә бизәлеше өчен декорация әзерләү | 2 сәг. | 04.12. 2025 | | |
| 26. | Практика | 2сәг. | 09.12. 2025 | | |
| 27. | Спектакльдән өзек өчен костюмнар һәм сәхнә бизәлеше өчен декорация әзерләү | 2 сәг. | 11.12. 2025 | | |
| 28. | Практика | 4 сәг. | 16.12. 2025<br>18.12. 2025 | | |
| 29. | Спектакльдән өзек өчен костюмнар һәм сәхнә бизәлеше өчен декорация әзерләү | 4 сәг. | 23.12. 2025<br>25.12. 2025 | | |
| 30 | Практика | 2 сәг. | 30.12. 2025 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 31 | Әсәрне мәктәп күләмендә сәхнәләштерү | 2 сәг. | 16.01. 2025 | | |
| 32 | Практика | 2 сәг. | 13.01. 2026 | | |
| 33 | Практика | 2 сәг. | 15.01. 2026 | | |
| 34 | “Театр яктылыкка, нурга илтә” БТХТга экскурсия уздыру. | 2 сәг. | 20.01. 2026 | | |
| 35 | Практика | 2 сәг. | 22.01. 2026 | | |
| 36 | “Яруллин укулары” исемле шигырьләрне сәнгатьле уку конкурсына әзерләнү | 2 сәг. | 27.01. 2026 | | |
| 37 | Практика | 2 сәг. | 29.01. 2026 | | |
| 38 | “Яруллин укулары” исемле шигырьләрне сәнгатьле уку конкурсына әзерләнү | 2 сәг. | 3.02. 2026 | | |
| 39 | репетиция | 2сәг. | 5.02. 2026 | | |
| 40 | Районның үзешчән артисты белән очрашып әңгәмә кору | 2 сәг. | 10.02.2026 | | |
| 41 | “Син театр турында нәрсәләр беләсең?” темасына викторина уздыру | 2 сәг. | 12.02 2026 | | |
| 42 | Балалар сәхнәләштергән видеоязмалар карау һәм аларны анализлау | 2 сәг. | 17.02. 2026 | | |
| 43 | Такмак әйтешле уеннар. | 4сәг. | 19.02, 24.02.2026 | | |
| 44 | Практика | 2 сәг. | 26.02. 2026 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 45 | Җитезлеккә уеннар өйрәнү. | 4сәг. | 03.03,05.03.2026 | | |
| 46 | Практика | 2 сәг | 10.03.2026 | | |
| 47 | Сәнгатьле уку буенча эш. | 2 сәг. | 12.03.2026 | | |
| 48 | Практика | 4 сәг. | 17.0319.03 2026 | | |
| 49 | Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү | 2 сәг. | 23.03. 2026 | | |
| 50 | Практика | 4 | 26.03.02.04. 2026 | | |
| 51 | Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү | 4 сәг. | 07.04.09.04.2026 | | |
| 52 | Практика | 6 сәг | 14.04,16.04.21.04. 2026 | | |
| 53 | Практика | 6 сәг. | 2 3.04,28.04,30.04 2026 | | |
| 54 | Практика | 4 сәг. | 05.05,12.05. 2026 | | |
| 55 | Йомгаклау | 2 сәг. | 19.05.2026 | | |